РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№4/9**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча 2020 елның 11 ноябрендә уздырылган ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай шәһәр Советының 2012 елның 19 декабрендәге 18/7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Чистай шәһәре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә (Чистай шәһәр Советының 2016 елның 30 июнендәге 7/1 номерлы, 25.08.2016 ел № 8/4, 27.04.2017 ел № 14/5, 28.09.2017 ел 18/4, 02.11.2017 ел №19/2, 14.12.2019 ел №20/13, 21.03.2018 ел №23/5, 29.08.2018 ел №27/1, 24.10.2018 ел № 28/5, 25.12.2018 ел №30/12, 28.02.2019 ел №32/1, 30.04.2019 ел №34/6, 11.06.2019 ел №35/4, 04.09.2019 ел №37/3, 27.11.2019 ел № 41/4, 11.02.2020 ел № 45/5, 13.05.2020 ел № 46/8, 02.09.2020 ел № 50/8, 28.10.2020 ел № 3/4 соңгы карарлары редакциясендә):

- Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Кызыл армия ур., 17 йорт чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:050402:12, 629,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерциячел билгеләнештәге зона» Д-1 зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта);
- СН-4 «Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Учхоз тыкрыгы, з/у 14Д

чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:180202:132, 2265 кв.м мәйданлы булган җир кишәрлеген, ТК-2 «III класслы хәвефлелектәге җитештерү-коммуналь объектлар зонасы» зонасына кертү өлешендә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

Чистай муниципаль районының
2020 елның 15 декабрендәге
4/9 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре территорияләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:



Чистай муниципаль районының
2020 елның 15 декабрендәге
4/9 номерлы карарына
2 нче кушымта

Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре территорияләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

